Республика Татарстан

**СОВЕТ СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Комсомола, д. 4а, с. Старый Кашир
423357
Телефон: 4-86-36

Татарстан Республикасы

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Иске Кәшер авылы, Комсомол урамы, 4а йорты, 423357
Телефон: 4-86-36

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 25 » ноябрь 2022 ел № 22

2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерү фаразы турында

«2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).

2. Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024-2025 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге
Советы Рәисе Р.Н.Дәүләтҗанов

1 нче кушымта

**2023 елга һәм 2024-2025 елларның план чорына**
**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы**

| Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап | Хисап | Бәя | Фараз | Фараз | Фараз |
| Халык саны | кеше | 791 | 781 | 781 | 785 | 785 | 785 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 0 | -0,99 | 0 | -1,01 | 0 | 0 |
| Эре мөгезле терлекләр саны | баш | 501 | 529 | 535 | 495 | 480 | 480 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 1,03 | 1,06 | 1,02 | -0,93 | 0,97 | 0 |
| Инвестицияләр | мең сум. | 252 | 262 | 262 | 280 | 300 | 320 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | -1,17 | 1,04 | 0 | 1,07 | 1,08 | 1,07 |
| Торак тапшыру | кв. м. | 147 | 67 | 67 | 100 | 100 | 100 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 0 | -0,46 | 0 | 1,5 | 0 | 0 |
| Хезмәт өчен түләү фонды | мең сум. | 18133.3 | 18840,5 | 20441,9 | 22670,1 | 24574,4 | 26564,9 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | -0,96 | 1,04 | 1,09 | 1,11 | 1,09 | 1,08 |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум. | 33580,2 | 34889,8 | 37855,4 | 41981,7 | 45508,1 | 49194,3 |
| Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | кеше | 45 | 45 | 45 | 45 | 45 | 45 |
| Эшмәкәрләр саны (КФХ)) | кеше | 12 | 14 | 12 | 10 | 10 | 4 |
| Эшсезләр саны | кеше | 3 | 3 | 2 | 2 | 2 | 2 |

Иске Кәшер авыл җирлеге хисапчысы: Г.Х.Юсупова

**2023 елга һәм 2042-20235елларның план чорына**
**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**Иске Кәшер авыл җирлеге**
**социаль-икътисадый үсеш фаразына**
**аңлатма язуы**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы **Иске Кәшер** авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнары статьяларын формалаштыру өчен кирәкле төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

Сарман муниципаль районы **Иске Кәшер** авыл җирлегенең 2021-2023 еллар чорына социаль-икътисадый үсеше фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән 2023-2025 елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы **Иске Кәшер** авыл җирлегенең 2022 елда көтелә торган нәтиҗәләрен һәм 2023-2025 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләрен исәпкә алып, 2021-2023 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм дефлятор-индексларны кулланып эшләнде.

2023-2025 елларда «Urals» нефтенә бәяләрнең баррель өчен 71,4-61,2 АКШ доллар дәрәҗәсендә уртача динамикасы фаразлана.

2023 елда долларның уртача еллык курсы АКШ доллары өчен 71 сум, 2024 елда – 78,7 сум дәрәҗәсендә булыр дип фаразлана. 2025 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 81сум тәшкил итәчәк.

Иске Кәшер авыл җирлеге алты торак пункттан тора: **Иске Кәшер**, **Урта Кәшер , Анак, Баткак, Яхшыбай** һәм **Яшьләр** авыллары.

Сарман муниципаль районы **Иске Кәшер** авыл җирлегенең 2023 елга халык саны 785 кеше тәшкил итәчәк, 2022 елга-785 кеше, 2023 елга-785 кеше.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «АГРОСИЛА ГРУПП» ООО Агрофирма «Җәлил» агрофирмасы ҖЧҖ, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның булган потенциалын һәм үсеш тенденцияләрен, шулай ук «Развитие АПК» программасын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып һәм «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программасын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Җәлил» агрофирмасы ҖЧҖ, «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖ һәм Латифуллин , Хасанов . крестьян-фермер хуҗалыклары эшчәнлеге алып барыла.

2022 елда төп капиталга инвестицияләр якынча 262000 сум тәшкил итәчәк. 2023 елда 280000 млн.сум күләмендә фаразлана, 2024-2025 елларда үсеш темпы 1,1 һәм 300 000 һәм 320000млн. сум тәшкил итәчәк.

2023-2025 елларда 100 квадрат метр торак файдалануга тапшыру планлаштырыла.

2022 елда хезмәт хакы фонды 20441,9 мең сум тәшкил итәчәк.

2023 елга хезмәт хакы фондының фаразланган күрсәткече –22670,1 сум, 2024 елда – 24574,4 сум, 2025 елда- 26564,9 сумнан артык.

Хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны 45кеше тәшкил итә.

Уртача айлык хезмәт хакы 2022 елда 37855,4сум, 2023 елга ул 41981,7 сум, 2024 елда – 45508,1 сум, 2025 елда 49194,3 сум тәшкил итәчәк.

Эшмәкәрләр саны 2023 елга 12 кеше тәшкил итәчәк, 2024 елга- 12 кеше, 2025 елга- 12 кеше.